МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.03.2026 Казан ш. № 07-51

"Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү хакында" Татарстан Республикасы Финанслар Министрлыгының 2017 елның 29 декабрендәге 07-142 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

"Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү хакында" Татарстан Республикасы Финанслар Министрлыгының 2017 елның 29 декабрендәге 07-142 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада "Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл кылуга" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасы муниципаль районнарында яшәүчеләрнең тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләр) хәл кылуга" дигән сүзләргә алыштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары А.Л.Анфимовага йөкләргә";

Бу боерык белән расланган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибендә:

1 пунктта "Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл кылуга" дигән сүзләрне «"Татарстан Республикасы муниципаль районнарында яшәүчеләрнең тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләр) хәл кылуга" дигән сүзләргә алыштырырга;

Бу Тәртипкә кушымтада:

атамасында “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл кылуга” дигән сүзләрне “Татарстан Республикасы муниципаль районнарында яшәүчеләрнең тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләр) хәл кылуга” дигән сүзләргә алыштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар средстволары хисабына, гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итү нигезендә гамәлгә ашырыла торган, халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне) хәл кылу чараларын башкару турында мәгълүматлар

Үлчәү берәмлеге: сумнарда

| № п/п | Халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләсе (җирле әһәмияттәге мәсьәлә) атамасы | Чара | Касса чыгымы, сумнарда | шул исәптән: | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Гражданнарның үзара салым средстволары хисабына касса чыгымы | Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар средстволары хисабына касса чыгымы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барлыгы” | | | | | |

Министр М.Җ.Фәйзрахманов